ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.01.2021 г. № 01

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 3 августындагы 504 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре тарафыннан адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 4 сентябрендәге 1355 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 3 августындагы 504 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре тарафыннан адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны матбугат басмасында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН МКУ * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ» МКУ
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 11 нче гыйнвар
01 нче номерлы карары белән расланган
кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 3 августындагы 504 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре тарафыннан адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр

1. 1.4 пункт үз көчен югалткан дип танырга.
2. 1.5 пунктны 1.4 пункт дип санарга.
3. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» 2 бүлегенең өченче баганасында «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив акт»ны үз көчен югалткан дип танырга.
4. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.4 пунктында «18 көн» сүзләрен «10 көн» сүзләренә алмаштырырга.
5. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» 2 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 2.4.1 пункт өстәргә:

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге |
|---|---|
| 2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен хокукый нигезләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон), (РФ законнары җыелмасы, 06.10.2003, № 40, 3822 ст.);<br>«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст.);<br>«Федераль адреслы мәгълүмат системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга (алга таба – 443-ФЗ номерлы Федераль закон) үзгәрешләр кертү хакында» |

| | |
|---|---|
| | 2013 елның 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон («Россия Федерациясе законнары җыелмасы», 30.12.2013, № 52 (I өлеш), 7008 ст.);<br>«Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында» (алга таба – Кагыйдәләр) 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары («РФ законнары җыелмасы», 01.12.2014, № 48, 6861 ст.);<br>«Планлаштыру структурасы элементлары, урам-юл челтәре элементлары, адреслау объектлары элементлары, адрес реквизитлары буларак файдаланыла торган биналар (корылмалар), урыннар типлары исемлеген һәм Адрес барлыкка китерүче элементларның кыскартылган исеме кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 5 ноябрендәге 171н номерлы Россия Финанс министрлыгы боерыгы (алга таба – 171н номерлы боерык) ("Российская газета», № 294, 28.12.2015);<br>«Адреслау объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турында гариза формаларын һәм адреслау объектына адрес бирү яисә аның адресын гамәлдән чыгарудан баш тарту турында карарны раслау турында» 2014 елның 11 декабрендәге 146н номерлы Россия Финанс министрлыгы боерыгы (алга таба - 146н номерлы боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru 12.02.2015);<br>«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Республикасы, 155-156 номерлары, 03.08.2004);<br>Түбән Кама муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Түбән Кама муни- |

| | |
|---|---|
| | ципаль районы Уставы;<br>әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә авыл җирлеге Уставы, (алга таба - Устав). |

6. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«146н номерлы боерык белән расланган форма буенча гариза.

Гариза мөрәҗәгать итүче яисә мөрәҗәгать итүче вәкиле тарафыннан имзалана.

Мөрәҗәгать итүче вәкиле тарафыннан гариза биргәндә, мондый гаризага мөрәҗәгать итүче вәкиленә бирелгән, Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә теркәлә.

Гариза  кадастр инженеры тарафыннан тапшырылганда, мондый гаризага адреслау объекты булган әлеге күчемсез милек объектына карата аның нигезендә кадастр эшләрен яки комплекслы кадастр эшләрен үтәү гамәлгә ашырыла торган «Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясында яки 42.3 статьясында каралган документ күчермәсе теркәлә.

Электрон документ рәвешендә гариза аның төре «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 21.1 статьясындагы 2 өлеше нигезендә билгеләнә торган мөрәҗәгать итүче яисә мөрәҗәгать итүче вәкиленең электрон имзасы белән имзалана.

Мөрәҗәгать итүче вәкиле тарафыннан электрон документ формасында гариза биргәндә, мондый гаризага ышаныч кәгазен биргән (имзалаган) зат тарафыннан, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып (гариза бирүче вәкиле ышанычнамә нигезендә эш иткән очракта) имзаланган электрон документ рәвешендә тиешенчә рәсмиләштерелгән ышанычнамә теркәлә

Мөрәҗәгать итүче яисә мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхсән мөрәҗәгатендә гариза биргән очракта, гариза бирүченең яисә мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен таныклаучы документ күрсәтелә.

Юридик зат исеменнән ышанычнамәсез эш итү хокукына ия зат шәхесен таныклаучы документ күрсәтә, ә юридик зат вәкиле шулай ук шушы юридик зат исеменнән эш иткәндә аның вәкаләтләрен раслаучы документ яки аның җитәкчесенең мөһере һәм имзасы белән таныкланган әлеге документның күчермәсен күрсәтә.

Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) тарафыннан Башкарма комитетка почта аша кәгазьдә җибәрелә яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән яки электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба - бердәм портал) яисә дәүләт һәм

муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) региональ порталларын (алга таба – региональ портал), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Федераль адреслы мәгълүмат системасы порталы (алга таба – адреслы система порталы) кулланып тапшырыла.».

7. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.6 пунктында:

беренче-унынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентның 2.3 пунктында каралган, алар нигезендә Башкарма комитет тарафыннан карарлар кабул ителә торган документларга түбәндәгеләр керә:

а) адреслау объектына (объектларына) хокук билгели һәм (яисә) хокук таныклый торган документлар (бинага (төзелеп килә торган бинага) яки корылмага адрес биргән очракта, шул исәптән аларның төзелеше тәмамланмаган, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, төзелеш өчен рөхсәт алу таләп ителми торган, күрсәтелгән бина (төзелеп килә торган бина) урнашкан җир кишәрлегенә хокук билгели һәм (яисә) хокук таныклый торган документлар);

б) күчемсез милек объектлары турында Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә, аларның үзгәртеп корылуы нәтиҗәсендә адреслау объектының бер һәм аннан да күбрәк барлыкка килүе (бер яки аннан да күбрәк адреслау объектлары барлыкка килү белән күчемсез милек объектларын үзгәртеп корган очракта);

в) адреслау объектын төзүгә рөхсәт (төзелә торган адреслау объектларына адрес биргәндә) (әгәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә бинаны (төзелеп килә торган бинаны), корылманы төзү яки үзгәртеп кору өчен, корылманы төзүгә рөхсәт алу таләп ителмәсә һәм (яки) адреслау объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт булганда;

г) адреслау объектының кадастр планында яки тиешле территориянең кадастр картасында урнашу схемасы (җир кишәрлегенә адрес бирелгән очракта);

д) адреслау объекты булган күчемсез милек объекты турында Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (кадастр исәбенә куелган адреслау объектына адрес бирелгән очракта);

е) җирле үзидарә органының торак урынны торак булмаган урынга яки торак булмаган урынны торак урынга күчерү турында карары (торак урынны торак булмаган урынга яки торак булмаган урынны торак урынга күчерү нәтиҗәсендә урынга адрес бирү, үзгәртү һәм мондый адресны гамәлдән чыгару очрагында);

ж) бер һәм аннан күбрәк яңа адреслау объектлары барлыкка килүгә китерә торган бинаны үзгәртеп корганда һәм (яки) яңадан планлаштырганда кабул итү комиссиясе акты (бер яки аннан күбрәк яңа адреслау объекты барлыкка килгән күчемсез милек объектларын (биналарны) үзгәртеп корганда);

з) адреслау объекты булган, дәүләт кадастр исәбеннән төшерелгән күчемсез милек объекты турында Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адреслау объекты адресын гамәлдән чыгарган очракта);

и) адреслау объекты булган күчемсез милек объекты буенча соратып алына торган белешмәләрнең Бердәм дәүләт реестрында булмавы турында хәбәрнамә (Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адреслау объекты адресы гамәлдән чыгарылган очракта).

унберенче абзацта «күрсәтелгән документлар» сүзләрен «әлеге пунктның «а», «в», «г», «е» һәм «ж» пунктчаларында күрсәтелгән документлар» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге пунктның «б», «д», «з» һәм «и» пунктчаларында күрсәтелгән документлар, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрне бирү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләте бирелгән, яки вәкаләтле орган таләбе буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә аның буйсынуында булган федераль дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелгән орган карары нигезендә эш итә торган федераль башкарма хакимият органы тарафыннан тапшырыла.».